Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Түбән Кәчи авыл җирлегенең Түбән Кәчи авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 19 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 17 номерлы Әлки муниципаль районының «Түбән Кәчи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Кәчи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 окябрендәге 16 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Кәчи авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Кәчи авыл җирлегенең Түбән Кәчи авылында гражданнар җыенының 2019 елның 19 ноябрендәге 1 номерлы беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Кәчи авыл җирлеге составына керүче Түбән Кәчи авылында гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

**2.** «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Кәчи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
алардан:

- парк территорияләрен коймалау, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру өчен түләү белән бәйле чыгымнарга-130 сум;

- авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту белән бәйле чыгымнарга-310 сум;

-су башнялары территорияләрен койма белән әйләндереп алу, төзелеш, реконструкция, кулланылган электр өчен түләү белән бәйле чыгымнар, операторга килешү буенча түләү һәм урам су белән тәэмин итү системасын ремонтлау өчен түләүгә -100 сум;

- урам утларын урнаштыруга кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләре, хезмәт күрсәтү һәм урам утларын кулланган энергиягә түләүгә бәйле чыгымнарга - 60 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Кәчи авыл жирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
алардан:

- парк территорияләрен коймалау, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру өчен түләү белән бәйле чыгымнарга-130 сум;

- авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту белән бәйле чыгымнарга-310 сум;

-су башнялары территорияләрен койма белән әйләндереп алу, төзелеш, реконструкция, кулланылган электр өчен түләү белән бәйле чыгымнар, операторга килешү буенча түләү һәм урам су белән тәэмин итү системасын ремонтлау өчен түләүгә -100 сум;

- урам утларын урнаштыруга кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләре, хезмәт күрсәтү һәм урам утларын кулланган энергиягә түләүгә бәйле чыгымнарга - 60 сум;

4.Гражданнар жыены нәтиҗәләрен Түбән Кәчи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Түбән Кәчи авыл жирлеге башлыгы: М. И. Елифанов